# Дәрес темасы:

**Җөмлә . Җөмлә ахырында тыныш билгеләре.**

# Максат :

- Җөмләдә һәр сүзнең үз урынын билгеләү күнегүләре;
- сорауларга җавап бирү;
- нәтиҗә ясау, кагыйдә формалаштыру.

Җөмлә тәмамланган уйны белдерә.
Җөмләнең беренче сүзе баш хәреф белән языла.
Җөмлә беткәч, нокта (.) куела.

Иң кечкенә җөмлә бер сүздән тора.

Тыныч тавыш белән хәбәр ителгән җөмләдән соң нокта (.) куела.

Хис белән хәбәр итүне, өндәүне белдергән җөмләләр ахырында өндәү билгесе (!) куела.

Сорауны белдергән җөмлә ахырында сорау билгесе (?) куела.

# Җөмлә төзе

**Куркак ,яши,<br>урманда,куян.**



***Биредә ничә җөмлә бар? Санын күрсәт.***

**Куян**

Кыш җитә салкын җил исә куян салкыннан курыкмый аның туны җылы кар ак куян да ак.



## Сүзләрне мәгънәләре буенча туры китереп, җөмләләр төзе.

Тиздән ______ җәй җитәр.
Безнең көтеп алган ____________ башланыр.Без елгада су _____һәм кояшта кызынырбыз.
Урманнарда ______ җиләкләр ашарбыз.
Болыннарда  матур_______ җыярбыз.
Рәхәтләнеп __ итәрбез!

коенырбыз

каникуллар

чәчәкләр

Ямьле

тәмле

ял

